Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXVII-14**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 29 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында мәгълүматлар өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 маддәләренә, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән 2022 елның 19 октябрендә килештерелгән 10-53/12905 номерлы уңай бәяләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2019 елның 13 августындагы XXXVIII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына түбәндәге торак пунктларның чикләре турында мәгълүматлар өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

Анатыш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Шиланка авылы;

Балыклы Чүкәй авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Балыклы Чүкәй авылы, Керәшен Казысы авылы, Иске Арыш авылы;

Биектау авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Биектау авылы, Чаллыбаш авылы, Янавыл авылы;

Олы Әшнәк авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Югары Әшнәк поселогы, Кече Әшнәк авылы;

Казак Чаллысы авыл җирлеге чикләрендә урнашкан с Казак Чаллысы авылы, Бирдебәк авылы, Зур Кадрәк авылы, Иванаево авылы, Кече Кадрәк авылы, Үри Чаллысы авылы;

Корноухово авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Корноухово авылы, Зюзино авылы, Наумово авылы, Шетнев-Чирмешән авылы;

Күгәрчен авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Күгәрчен авылы, Зәңгәркүл авылы;

Күки авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Күки авылы;

Котлы Бөкәш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Котлы Бөкәш авылы, Мәмли Казак Чаллысы авылы, Сатлыган авылы, Тәберде Чаллысы авылы;

Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Түбән Тегермәнлек авылы;

Яңа Арыш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Яңа Арыш авылы;

Уракчы авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Уракчы авылы, Мельничный Пүчинкәсе авылы, Николаевка авылы;

Шомарбаш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Шомарбаш авылы, Алан-Полян авылы, Таулар авылы;

Югары Ырга авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Югары Ырга авылы, Яңа Ырга авылы;

Шумково авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Шумково авылы, Олы Укмас авылы, Әшнәк-Качкалак авылы, Хутор авылы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгы
урынбасары — Ф.Г. Әхмәтҗанова